**Бәтке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү**

1. Бәтке авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча **халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итәбез.**

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
- Шәһәр төзелеше регламентлары;
- Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен куллану, күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.

**3. Проект буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча халык тыңлаулары 2026 елның 11 сентябреннән 2026 елның 25 сентябренә кадәр үткәрелә.

Халык тыңлауларын үткәрү процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- халык тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Халык тыңлауларында катнашучылар даирәсе:**

- Бәтке авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Бәтке авыл җирлеге чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре,
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Чикләрендә халык тыңлаулары уздырыла торган территория:** Бәтке авыл җирлеге.

**6. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы: 18.09.2026**

- Кама п., түбәндәге адрес буенча; Ключевая ур., 7 йорт, торак йорт янында;
- Нефтебаза п., түбәндәге адрес буенча: Үзәк ур., 21 йорт, торак милекчеләре ширкәте бинасы янында;
- Круглое Поле авылы, түбәндәге адрес буенча: Үзәк ур., 913 уч. (Ивушка бакчачылык коммерциясез ширкәте идарәсе бинасы янында);
- Бәтке авылы, түбәндәге адрес буенча: Гагарин ур., 2 йорт, авыл мәдәният йорты янында.

**7. Проект экспозициясен үткәрү сроклары:** 2026 елның 18 сентябреннән 2026 елның 25 сентябренә кадәр.

**8. Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:** дүшәмбе-җомга 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр.

**9. Халык тыңлауларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:**

2026 елның 18 сентябреннән 2026 елның 25 сентябренә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык

тыңлауларында катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язма яки телдән;

- халык тыңлауларын оештыручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты адресына язма рәвештә яки электрон документ формасында түбәндәге адрес буенча: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 101 каб.;

- Бәтке авыл җирлеге авыл мәдәният йортында халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозициясен карарга килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән түбәндәге адрес буенча: Бәтке авылы, Гагарин ур., 2 йорт.

**10. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат: 25.09.2026**

- 16:00 Кама п., түбәндәге адрес буенча; Ключевая ур., 7 йорт, торак йорт янында;

- 16:25 Нефтебаза п., түбәндәге адрес буенча: Үзәк ур., 21 йорт, торак милекчеләре ширкәте бинасы янында;

- 16:50 Круглое Поле авылы, түбәндәге адрес буенча: Үзәк ур., 913 уч. (Ивушка бакчачылык коммерциясез ширкәте идарәсе бинасы янында);

- 17:00 Бәтке авылы, түбәндәге адрес буенча: Гагарин ур., 2 йорт,авыл мәдәният йорты янында.

**11. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар** 2026 елның 18 сентябреннән Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) «Документлар/иҗтимагый һәм халык тыңлаулары» өстәмә битендә урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрнамәне** «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Бәтке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында урнаштырырга (tukay.tatarstan.ru)..

Тукай муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе

ЕМСЭД
Республики Татарстан
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 15AE296FD75F49CE6CBF538F55CA0DD1
Владелец: Маняпов Линар Нурисламович
Действителен с 11-11-2025 до 04-02-2027

Л.Н. Маняпов